ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 декабря 2024г. № 8023

Башкарма комитетның 2022 елның 1 сентябрендәге 4432 номерлы Карары белән расланган «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшырту» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 1 сентябрендәге 4432 номерлы Карары белән расланган «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшырту» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 бүлектә:

- «Программаны төп эшләүчеләр – программаның координаторы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны төп эшләүчеләр – программаның координаторы | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе»; |

- «Программаны үтәүчеләр» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны үтәүчеләр | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе»; |

- «Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе квартал саен һәм һәр ел йомгаклары буенча программаның тормышка ашыруга контрольне гамәлгә ашыра. Барлыкка килгән социаль-икътисадый хәлне исәпкә алып, программа чараларын аныклау буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертә». |

2) 5 бүлекне кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе Р.К. Шипеевага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 2 декабрендәге
8023 номерлы карарына
кушымта

5 бүлек. Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чараларын финанслау

| № т/б | Программа чараларының исеме | Программа чараларын башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Шул исәптән сроклар буенча (мең сум) | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2022 (база) | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| Максат – шәһәр оешмаларында хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшырту | | | | | | | | | | | |
| | Программа нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторы | | | Бәхетсезлек очракларының саны, берәмлек | 43 | 42 | 41 | 40 | | | |
| 1 бурыч. Производство травматизмы, беренче чиратта авыр һәм үлемгә китергән травматизм дәрәҗәсен киметү | | | | | | | | | | | |
| 1. | Хезмәтне саклау буенча Координация советлары үткәрү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | 2023-2025 еллар | Үткәрелгән утырышлар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | |
| 2. | Квартал саен хезмәтне саклау һәм аның шартларының торышы һәм производство травматизмын анализлау турында доклад әзерләү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | 2023-2025 еллар | Докладлар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Шәһәрнең ведомство карамагындагы белем бирү оешмаларында хезмәтне саклау торышы буенча тикшерү үткәрү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | 2023-2025 еллар | Үткәрелгән тикшерүләр саны, берәмлек | 20 | 20 | 20 | 20 | финанслау таләп ителми | | |
| 4. | Физик культура һәм спорт идарәсе карамагындагы учреждениеләрдә хезмәтне саклау торышы буенча тикшерү үткәрү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | 2023-2025 еллар | Үткәрелгән тикшерүләр саны, берәмлек | 17 | 17 | 17 | 17 | финанслау таләп ителми | | |
| 2 бурыч. Хезмәткәрләр өчен хезмәт эшчәнлеге процессында сәламәт һәм куркынычсыз хезмәт шартлары тудыру | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| 5. | Шәһәр оешмалары арасында хезмәтне саклау һәм аның шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыруга шәһәр смотр-конкурсы үткәрү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | 2023-2025 еллар | Конкурста катнашкан предприятиеләр саны, берәмлек | 65 | 67 | 69 | 71 | 30,0 | 30,0 | 30,0 |
| 6. | Хезмәтне саклау буенча басма белешмәлекләр (буклетлар, плакатлар) эшләү, әзерләү, аларны шәһәр учреждениеләрендә тарату | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | 2023-2025 еллар | Әзерләнгән материаллар саны, данә | 200 | 200 | 200 | 200 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7. | Бөтендөнья хезмәтне саклау көненә багышланган чара үткәрү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | 2023-2025 еллар | Үткәрелгән киңәшмәләр саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми |
| 8. | Шәһәр халкына оешмаларда хезмәтне саклау һәм хезмәт шартларының торышы турында мәгълүмат бирү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2023-2025 еллар | Басылып чыккан мәкаләләр саны | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми |
| Барлыгы: | | | | | | | | | 40,0 40,0 40,0 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева